**ГЛАВА СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КАМЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Урта Камышлы ав. **КАРАР**

**«10» октябрь 2025 ел** **№ 1**

**Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2025 елның 27 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Урта Камышлы авылы, Мәктәп урамы, 39нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасындаТатарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Красноармейская урамындагы 1-57нче йортларда, Мәктәп урамындагы 1-73нче йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 27 октябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Урта Камышлы авылы, Мәктәп урамы, 39нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасындаТатарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Совет урамындагы 1-54нче йортларда, Садовая урамындагы 1-15нче йортларда, Мәктәп тыкрыгы 1-12нче йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Урта Камышлы авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы территориясендә яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Урта Камышлы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту.

- Урамнарны яктырту җайланмасы;

- Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуция челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын уздыру датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы В.П. Вафина